**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4704**
**16.09.2019**

Башкарма комитетның «2015-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору өлкәсендә эшчәнлек оештыруны камилләштерү чаралары турында» 2015 елның 15 июлендәге 364 нче Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге УП-986 нчы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 10 сентябрендәге 763 нче карары, шәһәр Уставының 53 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2015-2020 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 7047 нче карарына (Башкарма комитетның 2014 елның 8 декабрендәге 7609 нчы, 2016 елның 30 мартындагы 1423 нче, 2016 елның 20 маендагы 2539 нчы, 2018 елның 12 мартындагы 1243 нче, 2018 елның 6 сентябрендәге 4995 нче, 2019 елның 29 мартындагы 1613 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдәге һәм 1 пункттагы «2015-2020» цифрларын «2015-2022» цифрларына алмаштырырга»;

2) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2015-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын финанслауны шәһәр бюджетының «Гомум дәүләткә караган башка мәсьәләләр» 01.13 һәм «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 851,8 мең сум, шул исәптән: 2015 елда – 20 мең сум, 2016 елда – 120,00 мең сум, 2017 елда – 120,00 мең сум, 2018

елда – 111,8 мең сум, 2019 елда – 120,00 мең сум, 2020 елда – 120,00 мең сум, 2021 елда – 120,00 мең сум, 2022 елда – 120,00 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

3) кушымтада:

- исемдәге «2015-2020» цифрларын «2015-2022» цифрларына алмаштырырга;

- 1 бүлектә:

«Муниципаль программаның исеме» дигән юлда «2015-2020» цифрларын «2015-2022» цифрларына алмаштырырга;

«Программаны эшләү өчен нигез (исеме, номеры һәм хокукый актның датасы)» дигән юлда «2015-2020» цифрларын «2015-2022» цифрларына алмаштырырга;

«Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм этаплары» дигән юлда «2015-2020» цифрларын «2015-2022» цифрларына алмаштырырга;

«Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары (еллар буенча бүлеп)» дигән юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | Тормышка ашыру чорына барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 20 | 120,00 | 120,00 | 111,8 | 120,00 | 120,00 | 120,00 | 120,00 | 851,8 |
| | Республика бюджеты | | | | | | | | | |
| | Федераль бюджет | | | | | | | | | |
| | Башка чыганаклар | | | | | | | | | |
| Искәрмә: финанслау күләмнәре прогноз характерында һәм ул Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, ел саен корректировкаланырга тиеш | | | | | | | | | | |

- 3 бүлекнең җиденче абзацында «2015-2020» цифрларын «2015-2022 цифрларына алмаштырырга;

- 4 бүлектә:

«Үтәү срогы» дигән баганада «2015-2020» цифрларын «2015-2022 цифрларына алмаштырырга»;

«Еллар буенча бүленгән чыгымнар суммасы, мең сум» баганасын «2021», «2022» баганалары белән тулыландырырга;

«Чараның исеме» дигән багананың 14 нче юлында «2015-2020» цифрларын «2015-2022» цифрларына алмаштырырга»;

«Башкаручы» дигән багананың 38, 45, 60, 61 нче юлларында Хакимнең (Шәһәр Советының) массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге (килешенү буенча)» сүзләрен «Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары
һәм программа чараларын финанслау

| Программаны тормышка ашыруның төп нәтиҗәлелек индикаторлары | Төп чараларны үтәү сроклары | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. | 6. |
| Яр Чаллы шәһәрендәге коррупция дәрәҗәсе (Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайты аша социологик сораштыру үткәрү юлы белән алынган мәгълүматлар буенча), % | ел саен | 35 | 35 | 35 | 33 |
| Коррупцион хокук бозулар кылган муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазыйфалар биләүче затларның саны, кеше | ел саен | 13 | 11 | 10 | 9 |
| Коррупция күренешләренә юлыккан гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен тикшерү нәтиҗәсендә ачылган хокук бозуларның өлеше, мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан чыгып, % | ел саен | 2 | 2 | 2 | 2 |

- 6 бүлекнең 3 пунктындагы «2013 елның 11 декабрендәге 7511 нче» сүзләрен «2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин